ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«21» апреля 2021 ел № 76-р

**Әгерҗе муниципаль районында «Тынычлык эстафетасы - 2021» массакүләм ярышлары үткәрү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 15 августындагы 1996-р номерлы “Татарстан кроссы - 2019” ярышларын уздыру турындагы күрсәтмәсе нигезендә:

1. 2021 елның 8 маенда Әгерҗе муниципаль районында Әгерҗе шәһәре, Ометов урамы адресы буенча «Тынычлык эстафетасы - 2021» массакүләм ярышын (алга таба - ярышлар) оештырырга һәм үткәрергә.

2. Расларга:

Әгерҗе муниципаль районында «Тынычлык эстафетасы - 2021» массакүләм ярышларын үткәрү турында нигезләмә (1 нче кушымта);

Әгерҗе муниципаль районында «Тынычлык эстафетасы - 2021» массакүләм ярышларын үткәрү турында чыгымнарның сметасын (2 нче кушымта);

Әгерҗе муниципаль районында «Тынычлык эстафетасы - 2021» массакүләм ярышы буенча спорт судьялары коллегиясенең составы (3нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының СОК МБУ «ОЛИМП»ка:

- "Тынычлык эстафетасы - 2021" массакүләм ярышларында катнашучыларны теркәү өчен урын, чишенү бүлмәсе бирергә;

- Әгерҗе шәһәренең Ометов урамында массакүләм ярышлар үткәрү урынын һәм дистанцияләр арасын әзерләргә.

4. МКУ «Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе»нә Әгерҗе муниципаль районы мәгариф оешмаларына «Тынычлык эстафетасы - 2021» массакүләм ярышларда катнашу турында хәбәр итәргә.

5. ДАССУ «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе»нә «Тынычлык эстафетасы - 2021» массакүләм ярышларда медицина персоналы белән тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе районы буенча Россия ЭЭМ бүлегенә «Тынычлык эстафетасы - 2021» массакүләм ярышлары вакытында җәмәгать тәртибен саклауны тәкъдим итәргә.

7. «Татмедиа» АҖ филиалының «Әгерҗе хәбәрләре» газетасына, «Әгерҗе радиосы”на ярышлар барышы һәм йомгаклары турында массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга тәкъдим итәргә.

8. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (https://agryz.tatarstan.ru) составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

9. Күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
21.04.2021 № 76-р
күрсәтмәсенә 1 нче кушымта

**Әгерҗе муниципаль районында «Тынычлык эстафетасы - 2021» массакүләм ярышларын үткәрү турында нигезләмә**

**1. Максат һәм бурычлар**

- районда спортны пропагандалау һәм үстерү
- халыкны физкультура һәм спорт белән массакүләм шөгыльләнүгә җәлеп итү
- районның иң көчле спортчыларын ачыклау.

**2. Ярышларны үткәрү вакыты һәм урыны**

Ярышлар 2021 елның 8 маенда Әгерҗе шәһәренең Ометов урамында уздырыла.

Ярышлар 13 сәгатьтә башлана, командаларны җыю һәм теркәү 12.30 сәгатьтән.

Ярышларның баш хөкемдары - Колчин А.В.- ТР Әгерҗе муниципаль районының “Спорт мәктәбе” МБУ тренеры.

Баш секретарь - Мөхәммәтҗанова Н.В.-ТР Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» МБУ СР директоры урынбасары.

**3. Үткәрү программасы һәм ярышларда катнашучылар**

Эстафетада катнашуга яшь категорияләре буенча район мәктәпләренең җыелма командалары кертелә:

1 узыш - 5-9 сыйныфлар;

2 узыш - 10-11 сыйныфлар;

3 узыш - хезмәт коллективлары, Түбән Кама агросәнәгать көллияте филиалы.

**Командалар составы:**

**5-9 класс** (5 малай + 5 кыз). Һәр параллельдән 1 малай һәм 1 кыз. Һәр параллель этапта үз яшьтәшләре белән йөгерәләр. Эстафета Әгерҗе шәһәренең Ометов урамы буйлап өч түгәрәктә уза.

**10-11 класс** - 2 малай + 2 кыз. 10-11 сыйныф составына, мәктәпнең 11 сыйныфы булмаса, 5-9 сыйныф составына кермәгән 9 класс спортчылары кертелә.

**Хезмәт коллективлары, Түбән Кама агросәнәгать көллияте филиалы** – 2 ир-ат+2 хатын-кыз. Бер узыш түгәрәге.

**1 узыш 5-9 класс:**

1 этап - 9 нчы сыйныф малае 300 метр старт ала. Әгерҗе шәһәренең Ометов урамындагы «Олимп» СОК МБУ бинасыннан локомотив депо

юнәлешендә старт ала, «Локотех» оешмасына борылышка кадәр барып җитә, параллель юлга борыла, «Олимп» СОК МБУ бинасына кайта, эстафетаны тапшыра.

2 этап – 9 нчы сыйныф кызы 300 метр старт ала. «Олимп» СОК МБУ бинасыннан локомотив депоның ял йортына кадәр, эстафетаны тапшыра.

3 этап – 8 нчы сыйныф малае 400 метр старт ала. Локомотив депосының ял йортыннан Ометов урамындагы 15 нче йортка кадәр, эстафетаны тапшыра.

4 этап - 8 нчы сыйныф кызы 400 метр старт ала. Ометов урамындагы 15 нче йорттан «Олимп» СОК бинасына кадәр, эстафетаны тапшыра.

5 этап – 7 нчы сыйныф малае 300 метр старт ала. «Олимп» СОК МБУ бинасыннан локомотив депоның ял йортына кадәр, эстафетаны тапшыра.

6 этап- 7 нчы сыйныф кызы 400 метр старт ала. Локомотив депосының ял йортыннан Ометов урамындагы 15 нче йортка кадәр, эстафетаны тапшыра.

7 этап- 6 нчы сыйныф малае 400 метр старт ала. Ометов урамындагы 15 нче йорттан «Олимп» СОК бинасына кадәр, эстафетаны тапшыра.

8 этап- 5 нчы сыйныф малае 300 метр старт ала. Олимп» СОК МБУ бинасыннан локомотив депоның ял йортына кадәр, эстафетаны тапшыра.

9 этап- 5 нчы сыйныф кызы 400 метр старт ала. Локомотив депосының ял йортыннан Ометов урамындагы 15 нче йортка кадәр, эстафетаны тапшыра.

10 этап- 5 нчы сыйныф малае 400 метр старт ала. Ометов урамындагы 15 нче йорттан «Олимп» СОК бинасына кадәр. Финиш.

**2 һәм 3 узыш 10-11 класс, хезмәт коллективлары, Түбән Кама агросәнәгать көллияте филиалы:**

1 этап ир-малай 300 метр старт ала, Әгерже шәһәренең Ометов урамындагы «Олимп» СОК МБУ бинасыннан локомотив депо юнәлешендә старт ала, «Локотех» оешмасына борылышка кадәр барып җитә, параллель юлга борыла, «Олимп» СОК МБУ бинасына кайта, эстафетаны тапшыра.

2 этап кыз-бала 300 метр старт ала, «Олимп» СОК МБУ бинасыннан локомотив депоның ял йортына кадәр, эстафетаны тапшыра.

3 этап ир-малай 400 метр старт ала, Локомотив депосының ял йортыннан Ометов урамындагы 15 нче йортка кадәр, эстафетаны тапшыра.

4 этап кыз-бала 400 метр старт ала, Ометов урамындагы 15 нче йорттан «Олимп» СОК бинасына кадәр. Финиш.

## 4. Җиңүчеләрне билгеләү тәртибе. Бүләкләү

Команда зачетында урыннар финиш кәүсәсен үтү тәртибе буенча билгеләнә, эстафета таякчыгын тапшырганда хаталар булмаса. һәр йөгерүдә 1 урынны алган команда истәлекле Кубок һәм грамота белән бүләкләнә. Команда зачетында 1,2,3 урынны алган эстафетада катнашучылар медальләр белән бүләкләнә.

## 5. Финанслау.

Шәхси беренчелектә, команда зачетында бүләкләү чыгымнарын Татарстан Республикасы Әгерже районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм эшләре бүлеге күтәрә.

Татарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районы
Башкарма комитетының
21.04.2021 № 76-р
күрсәтмәсенә 2 нче кушымта

**Әгерже муниципаль районында «Тынычлык эстафетасы - 2021» массакүләм ярышларын үткәрү турында чыгымнарның сметасы**

| Товар | Исәбе | Штук өчен бәясе, сум | Бәя, сум |
|---|---|---|---|
| Кубоклар | 3 | 950с. | 2850 с |
| Грамоталар | 10 | 15 с. | 150 с. |
| Медальләр | 54 | 60 с. | 3240 с. |
| Барлыгы | | | 6240 с. |

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
21.04.2021 № 76-р
күрсәтмәсенә 3 нче кушымта

**Әгерҗе муниципаль районында «Тынычлык эстафетасы - 2021» массакүләм ярышы буенча спорт судьялары коллегиясенең составы**

1. Иманова Любовь Сергеевна (Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм эшләре бүлеге)
2. Колчин Алексей Владимирович («Спорт мәктәбе» МБУ)
3. Мөхәммәтҗанова Наталия Викторовна («Спорт мәктәбе» МБУ)
4. Тукай Гөлназ Рәшит кызы («Спорт мәктәбе» МБУ)
5. Добровольская Раушания Илдар кызы («ОЛИМП» СОК» МБУ)
6. Закиров Руслан Рәмзил улы («Спорт мәктәбе» МБУ)
7. Идиятов Илдар Рәмис улы («Олимп» СОК» МБУ)